**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3578**
**14.07.2022**

Башкарма комитетның 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү комиссиясенең 2022 елның 17 маендагы 4 номерлы, 2022 елның 23 маендагы 5 номерлы карарлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 15 сентябрендәге 5527 номерлы, 2017 елның 17 ноябрендәге 7048 номерлы, 2018 елның 7 маендагы 2523 номерлы, 2018 елның 18 октябрендәге 6197 номерлы, 2019 елның 30 апрелендәге 2266 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 5788 номерлы, 2020 елның 17 мартындагы 1259 номерлы, 2020 елның 30 мартындагы 1556 номерлы, 2020 елның 4 сентябрендәге 4391 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы 1401 номерлы, 2021 елның 26 мартындагы 2089 номерлы, 2021 елның 12 апрелендәге 2485 номерлы, 2021 елның 10 сентябрендәге 5965 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 7449 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 7907 номерлы, 2022 елның 5 маендагы 2341 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, кушымтада каралганча стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарын өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе  Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 14 июлендәге
3578 номерлы карарына
кушымта

Шәһәр сайтында http://nabchelny.ru/company/1907 бастырып чыгарылган,
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертелергә тиешле стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары исемлеге

| № т/б | Тәртип № | Объектның урнашу урыны (адрес) | Объектның тибы | Объект чикләренең борылыш нокталары координатлары | Объектның махсуслашуы | Объекттан файдалану |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | | | |
| 1. | 172.31 | Тынычлык проспекты, 7/01 бина районындагы тротуар буйлап | Павильон 61,5 кв.м | 469144.71 2322717.23<br>469146.59 2322710.53<br>469156.00 2322720.20<br>469151.68 2322724.38 | Җәмәгать туклануы хезмәтләре | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 2. | 172.32 | Тынычлык проспекты, «Муравейник» СҮ каршында, җирле юлга тоташа торган тротуар буендагы территория | Павильон 42 кв.м | 471069.93 2323949.53<br>471073.94 2323945.62<br>471079.17 2323950.99<br>471075.16 2323954.90 | Җәмәгать туклануы хезмәтләре | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 3. | 172.33 | Беляев проспектыннан төшкәндә, Ф. Табеев исемендәге яр буена кергәндә уң яктагы мәйданчыкта | Павильон 100 кв.м | 470677.47 2321053.94<br>470673.67 2321067.11<br>470651.81 2321060.93<br>470652.54 2321058.01<br>470671.62 2321063.37<br>470674.57 2321053.15 | Җәмәгать туклануы хезмәтләре | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева